ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
08.04.2020

КАРАР
ПР-66

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген туктатып тору һәм дежур
төркемнәр эшчәнлеген оештыру турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы нигезендә, Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар - эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 80 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Эш көне булмаган көннәрдә дежур төркемнәр турында» 2020 елның 27 мартындагы 3845/20 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген 13.04.2020 - 30.04.2020 кадәр туктатып торырга.
2. 13.04.2020 - 30.04.2020 кадәр Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә эшләми торган көннәрне игълан итү турында» 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы гамәлдә булмаган ата-аналарның балалары өчен дежур төркемнәр оештырырга. Түбәндәге балалар бакчаларында:
-ТР Актаныш муниципаль районы "Актаныш гомуми үсеш бирүче 2 нче санлы балалар бакчасы" МББМБУ
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы В.Х. Хәева-Хәмитҗановага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев